КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1051

«Чистай күпюнәлешле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен «Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә кушу юлы белән «Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» һәм «Чистай күпюнәлешле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениеләрен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр һәм урта звено белгечләрен әзерләү сыйфатын яхшырту һәм хезмәт ресурсларыннан нәтиҗәлерәк файдалану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Чистай күпюнәлешле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Чистай күпюнәлешле көллияте) «Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә (алга таба – Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы) кушу юлы белән «Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» һәм «Чистай күпюнәлешле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениеләрен үзгәртеп оештыру, аларның эшчәнлегенең төп максатларын һәм үзгәртеп оештырганнан соң, «Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе исемен саклау турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы тарафыннан гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законда әлеге максатларга каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумының гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән күздә тотылган үзгәртеп оештыру чараларын үткәрүне тәэмин итәргә;

2021 елның 1 гыйнварыннан Чистай күпюнәлешле көллиятендә белем алучыларны, Чистай күпюнәлешле көллияттә гамәлдә булган укы-укыту шартларын һәм программаларын саклап, ата-аналарының (законлы вәкилләренең) ризалыгы белән Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумына күчерергә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә үзгәртеп оештыру чаралары аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

30 көн эчендә:

Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумына тапшырылырга тиешле Чистай күпюнәлешле көллиятенең мөлкәт исемлеген, шул исәптән техник документациясен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен эшләргә;

Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумында белем алучылар әзерлек үтәчәк белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

60 көн эчендә Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы уставына үзгәрешләр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң:

30 көн эчендә Чистай күпюнәлешле көллияткә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә итү хокукында Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумына беркетергә;

120 көн эчендә Г.И.Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумына беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (чикләнмәгән вакытта) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 3, 4 нче пунктларын үтәгәннән соң, 30 көн эчендә аларны бу

карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын билгели торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин